**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Бохарай торак пунктында гражданнар җыены карары**

22.11.2019 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең Бохарай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең Бохарай авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру;
- санкцияләнмәгән чүплекләрдән каты көнкүреш калдыкларын чыгару;
- волейбол сеткасы һәм туп сатып алу;
- торак пункт эчендәге юлларга вак таш җәю;
- зиратны төзекләндерү (мәгълүмат стенды һәм эскәмия сатып алу һәм урнаштыру);
- һәйкәлне төзекләндерү (коймасын буяу);
- урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;
- балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бохарай авыл җирлеге башлыгы _______________ Р.И. Нуриев